**ГЛАВА СОВЕТА СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422622 с. Сокуры,
ул. Державина , д.12 а
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ районы СОКУРЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422622 Сокуры авылы,
Державино урамы, 12а нчы йорт,
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

---

**2024 елның «03» апреле** **01 номер**

# КАРАР

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында.

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, әйләнә-тирә мохитне саклау, территорияләрне планлаштыру өчен шартлар тудыру, физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы белән 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү турында» 2024 елның 7 мартындагы 12-РС номерлы карары белән, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**карар иттем:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен күздә тоткан үзгәртү буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Гавами тыңлаулар үткәрү датасы һәм вакыты - 2024 елның 14 маенда 10.00 сәгатьтә;

2.2. Үткәрү урыны - ТР Лаеш районы, Сокуры авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан Сокуры авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы;

2.3. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү срогы - 2024 елның 13 маена кадәр; язма рәвештә, эш көннәрендә Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлегенең башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча: ТР, Лаеш районы, Сокуры авылы, Мәктәп урамы, 1 й., гражданнар өчен мәҗбүри күрсәтелеп: фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урынын теркәү адресы, эш урыны һәм биләгән вазыйфасы, контактлы телефоннар; гражданнар төркеме өчен - фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, кайсы да булса иҗтимагый оешмаларга яисә берләшмәләргә керүләре (булса), яшәү урынын теркәү адреслары, контакт телефоннары, юридик затлар өчен - оешма бланкында, җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелеп.

2.4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының муниципаль берәмлекләре чикләрен күздә тоткан үзгәртү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кызыксынган затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлегенең башкарма комитетына, мәгълүмат басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан алып 2024 елның 13 маена кадәр (шул көнне кертеп) язма рәвештә түбәндәге адрес буенча тапшырылырга мөмкин: ТР, Лаеш районы, Сокуры авылы, Мәктәп урамы.1.

3. Башкарма комитет секретарена:

3.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган Иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрнамә әзерләргә;

3.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән 7 эш көне эчендә әлеге карарның 4.1 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.3. Ачык тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына ахыргы карар кабул итү өчен җибәрергә

4. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән дата һәм вакыт буенча ачык тыңлаулар үткәрергә;

5. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Сокуры**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.Н. Газизуллин**